РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» октября 2021 ел г. Альметьевск № 1505

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Хокукый мониторинг тәртибендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының үз көчен югалтуларын танырга:

«Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә (тапшырылган вәкаләтләр нигезендә) дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентын раслау турында» 2019 елның 29 октябрендәге 1908 номерлы карары;

«Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә (тапшырылган вәкаләтләр нигезендә) дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентын раслау турында» 2019 елның 29 октябрендәге 1908 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 10 мартындагы 322 номерлы карары.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

А.Н. Подовалов